ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 36-2-45, факс: (84379) 36-2-45.

2023 елның 13 ноябре №4

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 13 октябрендә «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?- Татар Борнашы авылында юлларга асфальт валчык белән җәю, дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 445 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 226 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 224 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 2 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнар җыены узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнарыннан тыш, Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында 1000 сум күләмендә үзара салым

кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме? – Татар Борнашы авылында юлларга асфальт валчык белән җәю, дигән сорау буенча карарны танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: С.В.Бурукин